**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

31.08.2019 № 306

**Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген һәм 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында**

Татарстан Республикасы товар базарларында конкурентлыкны үстерү өчен шартлар тудыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 апрелендәге 768-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында Конкурентлыкны үстерү стандарты нигезләмәләренә таянып:

1. Түбәндәгеләрне расларга:
Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген (1 нче кушымта);
2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») (2 нче кушымта).

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:
Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр базарлары исемлеген һәм 2016-2018 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм чаралары планын («юл картасы») раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 776 номерлы боерыгы;
Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр базарлары исемлеген һәм 2016-2018 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм чаралары планын («юл картасы») раслау турында» боерыгына үзгәреш кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 761 номерлы боерыгы.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты** ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның « 31 » августындагы
306 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр базарлары исемлеге**

1. Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләре базары.
2. Балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре базары.
3. Гомуми белем бирү хезмәтләре базары.
4. Урта һөнәри белем бирү хезмәтләре базары.
5. Югары белем бирү хезмәтләре базары.
6. Җылылык белән тәэмин итү базары (җылылык энергиясе җитештерү).
7. Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм төяп озату буенча хезмәтләр базары.
8. Күпфатирлы йортта бина милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм агымдагы ремонтлау эшләрен башкару базары.
9. Дарулар, медицина эшләнмәләре һәм шуңа бәйле товарларны ваклап сату хезмәтләре күрсәтү базары.
10. Электр энергиясен (егәрлеген) ваклап сату базарында электр энергиясен (егәрлеген) сату-алу базары.
11. Нефть продуктлары базары.
12. Медицина хезмәтләре күрсәтү базары.
13. Балалар ялы һәм сәламәтләндерү хезмәтләре базары.
14. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү базары.
15. Регуляр муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтү базары.
16. Регуляр муниципальара маршрутларда автомобиль транспортында пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтү базары.
17. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хезмәтләре күрсәтү базары.
18. Социаль хезмәт күрсәтү базары.
19. Мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр базары.
20. Элемтә хезмәте күрсәтү базары, шул исәптән югары тизлектәге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташтыру буенча хезмәтләр базары.
21. Ваклап сату базары.
22. Нәселле терлек үрчетү базары.
23. Торак төзелеше базары.

24. Торак һәм юл төзелешеннән тыш капиталь төзелеш объектлары төзү базары.
25. Архитектура-төзелеш проектлары әзерләү базары.
26. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә киң таралган файдалы казылмалар чыгару базары.
27. Шәһәр тирәлеген төзекләндерү буенча эшләр башкару базары.
28. Сыекландырылган балонлы газ белән тәэмин итү базары.
29. Генерация режимында электр энергиясен (егәрлек) ваклап сату базарында электр энергиясен (егәрлек) когенерация режимында (электр энергиясен (егәрлек) җитештерүне дә кертеп, җитештерү базары.
30. Кирпеч җитештерү базары.
31. Бетон җитештерү базары.
32. Җиңел сәнәгать базары.
33. Агач эшкәртү һәм агачтан эшләнмәләр җитештерү базары.
34. Автотранспорт чараларын ремонтлау буенча хезмәт күрсәтү базары.
35. Орлыкчылык базары.
36. Юл эшчәнлеге базары (проектлаудан тыш).
37. Судагы биоресурсларны тоту базары.
38. Судагы биоресурсларны эшкәртү базары.
39. Товарлыклы аквакультура базары.
40. Кадастр һәм җир төзелеше эшләре базары.
41. Тышкы реклама өлкәсе базары.

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның « 31 » августындагы
306 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

## 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планы («юл картасы»)

## I. 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планы («юл картасы») гомуми тасвирламасы

1.1. Конкурентлыкка ярдәм итү Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнә, Россия Федерациясенең конституциячел корылыш нигезләренең берсе, дәүләт сәясәтенең даими өстенлекле юнәлеше булып тора.

Икътисад тармакларында конкурентлыкны үстерү күпаспектлы бурыч булып тора, аны хәл итү шактый дәрәҗәдә күптөрле юнәлешләр буенча – макроикътисадый сәясәт, финанс һәм салым системасын үстерүне дә кертеп, уңай инвестиция климаты булдырудан башлап, административ һәм инфраструктура тармагында киртәләрне киметү, гражданнарның хокукларын яклау һәм милли сәясәт өлкәсендә дәүләт сәясәте уздыруның нәтиҗәлегенә бәйле.

1.2. 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча әлеге чаралар планы (алга таба – «юл картасы»ның) предметы булып конкурентлыкны үстерү юнәлешләре тора. Алар конкурентлыкны үстерү өчен махсус, системалы һәм зур әһәмияткә ия.

1.3. Конкурентлыкны үстерүнең төп күрсәткечләре һәм чаралары 2022 елның 1 гыйнварына хосусый бизнес икътисадының тармаклары (өлкәләр, товар базарлары) (тармакларда (өлкәләрдә, товар базарларында өлеше) өчен эшләнә.

**II. Татарстан Республикасы икътисадының (аерым товар базарларында) һәр тармагында (өлкәсендә) килеп туган вазгыятькә һәм аның проблематикасына карата факттагы башлангыч мәгълүмат (шул исәптән саннарда).**

2.1. «Юл картасы»нда һәр товар базары буенча әлеге товар базарында килеп туган вазгыятькә һәм аның Кыенлыклартикасына карата фактта мәгълүмат (шул исәптән, саннарда) китерелә, аңа түбәндәгеләр керә:

товар базарында хосусый милек рәвешендә хуҗалык итүче субъектларның өлеше турында мәгълүмат;

агымдагы вазгыятьне тасвирлау, төп мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү ысулларын анализлау белән бергә товар базарына хас үзенчәлекләр;

тиешле товар базарына керүнең төп административ һәм икътисадый киртәләре характеристикасы;

бизнес-берләшмәләр һәм кулланучылар арасында конкурентлык мохитенең торышын бәяләү;

базарның үсеш перспективалары.

2.2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 апрелендәге 768-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында Конкурентлыкны үстерү стандарты (алга таба – Стандарт) таләпләре нигезендә «юл картасы»нда конкурентлыкны үстерү өчен мәҗбүри булган төп күрсәткечләр билгеләнә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасында Стандарт тарафыннан билгеләнгән максатчан күрсәткечләргә ирешелгән, ләкин аларны хәл итүнең башка юлларын эзләү таләп ителгән мәсьәләләр калган берничә базар бар.

2.3. Мәгълүмат алу өчен Монополиягә каршы федераль хезмәт (алга таба – Россия МКФХ) тарафыннан расланган конкурентлыкны үстерүнең төп күрсәткечләрен исәпләү методикаларында күрсәтелгән чыганаклар кулланылды, шул исәптән:

Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәте территориаль органының (алга таба – Татарстанстат) статистика белешмәләре;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең профильле (тармак) башкарма органнары мәгълүматы;

салым органнары белешмәләре;

Татарстан Республикасы товар базарларында конкурентлык мохите торышын мониторинглау нәтиҗәләре;

конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан әзерләнгән һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясенең 2019 елның 7 мартындагы АП-12-61 номерлы беркетмәсе белән расланган 2018 елда Татарстан Республикасы товар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр базарларында конкурентлык мохите торышы һәм аны үстерү турында доклад.

| Т/с | Бурычны үтәү чарасының исеме | Максат индикаторлары | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор күрсәткече (конкурентлыкны үстерүнең төп күрсәткечләре) | | | | | Максат индикаторын исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 01.01.2018 | 01.01.2019 | 01.01.2020 | 01.01.2021 | 01.01.2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләре базары | | | | | | | | | | |
| | 2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында хосусый милек рәвешендәге 34 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы эшли, аларда 3 507 бала тәрбияләнә.<br>Мәгариф өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне финанс белән тәэмин итү «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 9 мартындагы 132 номерлы карары белән дәүләт аккредитациясе алган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый гомуми белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү оешмалары һәм хосусый эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе расланды. Субсидияләр мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем (алга таба – лицензия) программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган хосусый мәгариф оешмаларына, хосусый эшмәкәрләргә бирелә.<br>Лицензия алган хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын субсидияләү аларны лицензия алуга стимуллаштыра һәм әлеге базарда конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итә.<br>2018 елда субсидия алучылар – 14 хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, мәктәпкәчә төркемнәр белән 5 хосусый гомуми белем бирү оешмасы, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы 2 хосусый эшмәкәр. 2018 елда Татарстан Республикасы бюджетында әлеге максатларга 104,4 млн сум каралган, 2019 елга план 110 млн сумга үтәлгән.<br>Хәзерге вакытта «Демография» милли проекты кысаларында «өч яшькә кадәрге балалар өчен яслегә чиратны бетерүне дә кертеп, хатын-кызларның хезмәт белән мәшгульлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру» төбәк проекты гамәлгә ашырыла, аның нигезендә 2022 елга кадәр муниципаль мәктәпкәчә оешмаларда өстәмә 15 мең урын булдырылачак, бу исә балалар бакчаларына чиратның кимүенә китерәчәк. Шуңа бәйле рәвештә, хосусый балалар бакчаларына йөрүче балалар саны арту фаразланмый. | | | | | | | | | |
| | Кыенлыклар: ата-аналарның өчен түләүнең югары булуы сәбәпле хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына балаларның аз йөрүе | Бурыч: мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләре базарында конкурентлыкны үстерү өчен шартлар тудыру. | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Максат (төп күрсәткеч): хосусый белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның өлешен, төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы хосусый эшкуарларда – мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программаларын арттыру, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гомуми санын арттыру, төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы хосусый эшкуарларда – мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программаларын арттыру, процентларда.<br>Төп күрсәткечләр:<br>01.01.2018 – 1,5 %<br>01.01.2019 –1,52 %<br>Фаразлана торган күрсәткечләр:<br>01.01.2020 – 1,55 %<br>01.01.2021 – 1,57 %<br>01.01.2022 – 1,6 % | | | | |
| 1.1 | Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программаларын тормышка ашыручы хосусый мәгариф оешмаларының, хосусый эшкуарларның белем бирү эшчәнлегенә чыгымнарны субсидияләү | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы балаларның гомуми исәбендә хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы балаларның чагыштырма өлеше | процент | 1,50 | 1,52 | 1,55 | 1,57 | 1,60 | V = A / B x 100%, биредә: A – хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы балалар саны, кеше; B – мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы балаларның гомуми саны, кеше | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 1.2 | Дәүләт-хосусый партнерлык һәм муниципаль-хосусый партнерлык механизмнарын | Ачылган хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмалары саны | берәмлек | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | кулланып, яңа хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын ачу | | | | | | | | | |
| 2. Балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре базары | | | | | | | | | | |
| Хәзерге вакытта Татарстанстат мәгълүматлары буенча, 2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы хосусый милек рәвешендәге 22 оешма һәм башка милек рәвешендәге 7 оешма эшли. Өстәмә белем бирү программалары буенча 5 яшьтән 18 яшькә кадәр 9 033 бала шөгыльләнә. | | | | | | | | | | |
| | Кыенлыклар: өстәмә белем бирү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган сектор оешмалары тарафыннан норматив, хокукый, методик һәм консультация ярдәме җитмәү;<br>өстәмә белем бирү оешмаларының матди-техник базасының искергән булуы;<br>балаларга өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлегенә лицензиясе булган дәүләтнеке булмаган оешмаларның җитәрлек күләмдә булмавы (алга таба – БӨББ));<br>балаларга өстәмә белем бирүнең вариатив формаларының халыкның өстәмә белем бирү хезмәтләренә ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерә алырлык дәрәҗәдә булмавы | | | Бурыч: өстәмә белем бирү мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме алу өчен сайлап алуда катнашу мәсьәләләре буенча хокукый, методик һәм консультация ярдәме күрсәтү;<br>гражданнарның төрле ихтыяҗларын канәгатьләндерү, педагогик кадрларның квалификациясен күтәрү, өстәмә белем бирүнең заманча юнәлешләрен үстерү өчен балаларга өстәмә белем бирүнең вариатив формаларын тәкъдим итү;<br>өстәмә белем бирү оешмаларының матди-техник базасын яңарту һәм капиталь төзекләндерү программасын формалаштыру;<br>өстәмә белем бирүнең инновацияле программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру өлешендә өстәмә белем бирү системасы хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү программаларын үтәү.<br>Максат (төп күрсәткеч): балаларга мәктәпкәчә белем бирү хезмәте күрсәтү өлкәсендә хосусый милек рәвешендә булган оешмаларның өлешен арттыру, процентларда.<br>Төп күрсәткечләр:<br>01.01.2018 – 1,7 %<br>01.01.2019 – 1,9 %<br>Фаразлана торган күрсәткечләр:<br>01.01.2020 – 2,1 %<br>01.01.2021 – 2,3 %<br>01.01.2022 – 5 % | | | | | | |
| 2.1 | Белем бирү эшчәнлеген оештыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән | берәмлек | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министр- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәсьәләләре һәм субсидияләр бирү тәртибе буенча балаларга өстәмә белем бирүче хосусый милек рәвешендәге оешмаларга һәм физик затларга методик һәм консультация ярдәме күрсәтү | министрлыгының рәсми сайтында өстәмә белем бирү оешмалары эшчәнлеге буенча мәгълүмати һәм методик материаллар саны | | | | | | | | лыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, «Мәктәптән тыш эш республика үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе (килешү буенча) |
| 2.2 | Балаларга өстәмә белем бирү буенча хосусый учреждениеләр булдыруның билгеләнгән тәртибе (регламенты), балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыру турында эшкуарлык субъектларының мәгълүматын арттыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре сайтларында урнаштырылган методик күрсәтмәләр, балаларга өстәмә белем бирү һәм белем бирү эшчәнлеген лицензияләү буенча хосусый учреждениеләр булдыру тәртибе турында тәкъдимнәр саны | берәмлек | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Мәктәптән тыш эш республика үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. Гомуми белем бирү хезмәтләре базары | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 9 мартындагы 132 номерлы карары белән дәүләт аккредитация алган төп гомуми белем программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, төп урта, гомуми урта хосусый гомуми белем бирү оешмалары һәм хосусый эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе расланды. 2017 елда Татарстан Республикасында 11 хосусый гомуми белем бирү оешмасы эшләде, 2018 елда бу сан 15 кә җитте. 2017 елда башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем бирү буенча төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый мәгариф оешмаларының белем бирү эшчәнлегенә чыгымнарны субсидияләүгә 58,5 млн сум бүлеп бирелде, 2018 елда исә 86,9 млн сум, 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетында күрсәтелгән максатларга 84,7 млн сум каралган | | | | | | | | | | |
| | Кыенлыклар: Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары тарафыннан төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый мәгариф оешмаларына дәүләт яисә муниципаль преференцияләр җитәрлек бирелмәгән булуы | | | Бурыч: хосусый милек рәвешендәге гомуми белем бирү оешмаларында һәркемнең түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларын гамәлгә ашыруга дәүләт гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү<br>Максаты (төп күрсәткеч): төп гомуми белем бирү программалары – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында төп гомуми белем бирү программалары – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында укучыларның өлешен арттыру.<br>Төп күрсәткечләр:<br>01.01.2018 – 0,5 %<br>01.01.2019 – 0,55 %<br>Фаразлана торган күрсәткечләр:<br>01.01.2020 – 0,7 %<br>01.01.2021 – 0,8 %<br>01.01.2022 – 1 % | | | | | | |
| 3.1 | Хосусый милек рәвешендәге гомуми белем бирү оешмаларында һәркемнең түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта | Хисап чорында төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында (шул | процент | 0,5 | 0,55 | 0,7 | 0,8 | 1 | V = A / B x 100%, биредә: A – хисап чорында хосусый белем бирү оешмалары (шул исәптән аларның филиаллары) тарафыннан | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гомуми белем алуга хокукларын гамәлгә ашыруга дәүләт гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү | исәптән аларның филиалларында) укучыларның чагыштырма өлеше | | | | | | | күрсәтелгән башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча төп гомуми белем бирү хезмәтләре алган укучылар саны;<br>В – хисап чорында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы барлык белем бирү оешмалары тарафыннан (Россия Федерациясе өлеше 50% тан артык булган хуҗалык итүче субъектлардан, федераль дәүләт унитар предприятиеләреннән, дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт ширкәтләреннән, федераль бюджет оешмаларыннан, федераль автоном оешмаларыннан, федераль казна оешмаларыннан тыш) | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | күрсәтелгән гомуми белем бирү хезмәтләре алган укучыларның гомуми саны | |
| 3.2 | Дәүләт-хосусый партнерлык һәм муниципаль-хосусый партнерлык механизмнарын кулланып, яңа хосусый гомуми белем бирү оешмалары ачу | Ачылган хосусый гомуми белем бирү оешмалары саны | берәм-лек | 0 | 0 | 1 | 2 | 3 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4. Урта һөнәри белем бирү хезмәтләре базары | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы территориясендә 95 һөнәри белем бирү оешмасы эшли, шул исәптән 88 дәүләт һөнәри белем бирү оешмасы, 7 дәүләтнеке булмаган һөнәри белем бирү оешмалары.<br>Кадрлар әзерләү буенча ресурс үзәкләр. 2014 елдан ресурс үзәкләрен булдыру программасы гамәлгә ашырыла. Аларда әзерлек сыйфатын күтәрү өчен иң яхшы укыту-методик, кадрлар һәм матди-техник ресурслар тупланган, уку биналарына һәм остаханәләргә капиталь ремонт ясалган, уку җиһазлары китерелгән. Бүгенге көндә республикада 31 ресурс үзәге булдырылган, 2019 елда аларның саны 37 гә житәргә тиеш. Барлыгы алты ел эчендә (2014–2019 еллар) ресурс үзәкләрен булдыру чараларын гамәлгә ашыруга 5,1 млрд сумнан артык акча юнәлдерелгән. Планлы эш нәтиҗәсендә ресурс үзәкләренә ихтыяҗ арта. Алар республикабызның һәм Россиянең башка төбәкләреннән иң яхшы абитуриентларны җәлеп итү үзәгенә әверелә.<br>Татарстан Республикасы «Ворлдскиллс» хәрәкәтендә. Ресурс үзәкләре эшенең мөһим юнәлеше булып инновацион белем бирү технологияләрен апробацияләү, «Ворлдскиллс» стандартларын кертү тора. Ресурс үзәкләре исә төп катнашучылар булып тора. Бу эш министрлык һәм ведомстволардан килгән коллегалар белән нәтиҗәле хезмәттәшлектән, шулай ук партнер булып торучы оешмалар ярдәменнән башка мөмкин булмас иде. 2016 елда республикада «Ворлдскиллс» хәрәкәтенең төбәк координация үзәге – «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы төзелде.<br>Татарстан Республикасында дуаль укыту. 2014 елдан башлап республикада дуаль белем бирү практикасы гамәлдә, ягъни уку вакытының яртысыннан да ким булмаган өлешен студентлар база предприятиеләрендә үткәрә һәм аның тулы хокуклы хезмәткәрләре булып тора.<br>Белем бирү оешмаларының һәм житештерүнең нәтиҗәле хезмәттәшлегенең ачык мисаллары булып «Бөгелмә машина төзелеше техникумы» дәүләт автоном урта һөнәри белем бирү учреждениесенең «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Бөгелмә механика заводы белән берлектә, | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| В.Д. Шашин исемендәге «Алабуга политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең «Форд Соллерс» ширкәте белән берлектә һәм «Әлмәт һөнәр көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенең «Алнас» ачык акционер җәмгыяте белән берлектә дуаль белем бирүне гамәлгә ашыруы тора.<br>Республикада хезмәт базарында ихтыяҗ аеруча зур булган 50 һөнәр, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 2 ноябрендәге 831 номерлы боерыгы белән расланган яңа һәм перспективалы урта һөнәри белем бирү һөнәрләре исемлегендәге («ТОП-50» исемлеге) иң перспективалы һәм кирәкле белгечлекләр һәм һөнәрләр буенча белем бирү программалары гамәлгә кертелә. 2019 елдан башлап мондый программалар инде 24 булачак | | | | | | | | | | |
| | Кыенлыклар: «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри белем бирү оешмалары юнәлеше буенча демонстрацион имтихан үткәрүгә өстәмә финанс чыгымнарының расланган нормативларын бюджетка кертү зарурлыгы;<br>квалификацияле эшче кадрлар әзерләү мәсьәләләре буенча һөнәри белем бирү оешмаларының кече һәм урта бизнес оешмалары һәм предприятиеләре белән үзара бәйләнешенең тиешле дәрәҗәдә үсмәве. | | | Бурычлар: Татарстан Республикасында заманча стандартлар һәм технологияләр нигезендә югары квалификацияле белгечләр һәм эшче кадрларның заманча инфраструктурасын үстерү;<br>«Ворлдскиллс» стандартлары буенча белем бирү һәм тиешле квалификацияне бәяләү өчен һөнәри белем бирү оешмаларының кадрлар потенциалын формалаштыру;<br>Урта һөнәри белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен заманча шартлар һәм һөнәри әзерлек программалары белән өстәмә һөнәри белем бирү программаларын булдыру;<br>хезмәт базарының агымдагы һәм перспектив таләпләренә туры китереп, һөнәри белем бирү оешмалары базасында кадрлар әзерләү өчен шартлар тудыру;<br>«Россия Федерациясендә Цифрлы икътисад» милли программасы контекстында урта һөнәри белем бирүне модернизацияләү шартларында Татарстан Республикасы оешмаларында онлайн-белем бирүне үстерү.<br>Максат (төп күрсәткеч): төп гомуми белем бирү программалары – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында төп гомуми белем бирү программалары – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында укучыларның өлешен арттыру.<br>Төп күрсәткечләр:<br>01.01.2018 – 2,9 %;<br>01.01.2019 – 3 %<br>Фаразлана торган күрсәткечләр:<br>01.01.2020 – 3,5 %<br>01.01.2021 – 4 %<br>01.01.2022 – 5 % | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1 | ТОП-50 исемлегендәге белем бирү программаларын гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасының ТОП-50 исемлегендәге өстенлекле һөнәрләр, белгечлекләр буенча урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмалары саны | берәмлек | 20 | 24 | 26 | 27 | 28 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4.2 | Татарстан Республикасында «Ворлдскиллс» компетенцияләренең махсуслаштырылган үзәкләрен аккредитацияләү буенча эшләр үткәрү | «Яшь профессионаллар (Ворлдскиллс)» берлеге аккредитацияләнгән «Ворлдскиллс» компетенцияләренең махсуслаштырылган үзәкләре саны | берәмлек | 18 | 25 | 30 | 31 | 32 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4.3 | Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының матди-техник базасын үстерү | Һөнәри белем бирү оешмаларының матди-техник базасын үстерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы акчалары күләмен саклап калу | млн. сум | 670,6 | 670,7 | 670,8 | 670,9 | 671,0 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4.4 | «Ворлдскилс» стандарты буенча | «Ворлдскилс» стандартлары буенча | кеше | 1247 | 2800 | 4800 | 8000 | 9600 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы | Татарстан Республикасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасында демонстрацион имтихан үткәрү | демонстрацион имтихан тапшырган көндезге уку формасы буенча Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларында укучылар саны | | | | | | | таләп ителми | Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 5. Югары белем бирү хезмәтләре базары | | | | | | | | | | |
| 2018, 2019 уку елында Татарстан Республикасы территориясендә 46 югары белем бирү мәгариф оешмасы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра. Шул исәптән 26 төп белем бирү оешмасы, 20 югары белем бирү мәгариф оешмаларының филиалы.<br>Югары белем бирү программалары буенча 146 823 студент белем ала, шул исәптән: югары белем дәүләт мәгариф оешмаларында (филиаллары булган) – 126 544, дәүләтнеке булмаган югары белем бирү оешмаларында (филиаллары булган) – 20 279 студент. Республиканың югары белем бирү мәгариф оешмаларында югары белем бирүне әзерләү юнәлешләренең 54 зурайтылган төркеменең 53 ендә – бакалавриат буенча белем бирү алып барыла.<br>2019, 2020 уку елында дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирү мәгариф оешмалары арасында ачык бәйге нәтиҗәләре буенча югары белем бирү мәгариф оешмаларына федераль бюджеттан 16 312 контроль кабул итү саны бүлеп бирелгән, шуларның 63 проценты инженерлык-техник юнәлешләргә, 27 проценты гуманитар, 10 проценттан артыгы табигый-фәнни юнәлешләргә. | | | | | | | | | | |
| | Кыенлыклар:<br>аккредитацияләнгән белем бирү программаларын кыскарту;<br>югары белем бирүнең дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмалары тарафыннан әзерлек юнәлешләрендә тормышка ашырыла торган әзерлекнең түбән өлеше. | | | Бурычлар: аккредитацияләнгән белем бирү программалары санын киңәйтү.<br>хосусый милек рәвешендәге белем бирү оешмаларын федераль һәм региональ программалар һәм проектлар чараларын тормышка ашыруга җәлеп итү.<br>Максат (төп күрсәткеч): хосусый милек рәвешендәге югары белем бирү оешмаларының өлешен арттыру, процентларда.<br>Төп күрсәткечләр:<br>01.01.2018 – 36 %<br>01.01.2019 – 36,5 %<br>Фаразлана торган күрсәткечләр:<br>01.01.2020 – 37 %<br>01.01.2021 – 38 %<br>01.01.2022 – 39 % | | | | | | |
| 5.1 | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм | Төбәк, федераль программаларда, | берәмлек | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы | Татарстан Республикасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фән министрлыгы тарафыннан хосусый югары белем бирү оешмаларына төбәк, федераль программаларны, проектларны гамәлгә ашыруда катнашулары кысаларында ярдәм күрсәтү | проектларда катнашучы Татарстан Республикасында урнашкан хосусый милек рәвешендәге югары белем бирү оешмалары саны | | | | | | | таләп ителми | Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 5.2 | Татарстан Республикасы икътисадының квалификацияле кадрларга ихтыяҗларын һәм халыкның белем бирү хезмәтләренә ихтыяҗын исәпкә алып, Татарстан Республикасында урнашкан хосусый милек рәвешендәге югары белем бирү мәгариф оешмаларына бүлеп бирү планлаштырыла торган кабул итүнең контроль саннары күләмнәре буенча мәгариф өлкәсендә дәүләт хакимиятенең федераль органына тәкъдимнәр җибәрү | Федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбенә укуга кабул итүнең контроль саннарын алучы Татарстан Республикасында урнашкан хосусый милек рәвешендәге югары белем бирүче мәгариф оешмалары саны | берәмлек | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

<table>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td><td>10</td><td>11</td></tr>
<tr><td colspan="11">6. Җылылык белән тәэмин итү базары (җылылык энергиясе җитештерү)</td></tr>
<tr><td colspan="11">2018 елда Татарстан Республикасында барлыгы 80 торак-коммуналь һәм ягулык-энергетика комплексы оешмасы кулланучыларны җылылык энергиясен белән тәэмин итте, шуларның 39ы Татарстан Республикасына оешмасы, шул исәптән 10 муниципаль унитар предприятие.<br>2018 елда Татарстан Республикасы оешмалары тарафыннан бирелгән җылылык энергиясенең гомуми күләме 40 718 мең Гкал тәшкил итте, шул ук вакытта хосусый оешмалар өлешенә 27 212 мең Гкал туры килә, бу җылылык энергиясенең 67% ын тәшкил итә. Әлеге күрсәткеч бу базарның төп күрсәткеченнән сизелерлек артып китә, бу шулай ук республиканың коммуналь комплексында дәүләт-хосусый партнерлык программаларын актив тормышка ашыру нәтиҗәсе булып тора.<br>Шул ук вакытта, Татарстан Республикасының җылылык белән тәэмин итү базары коммуналь объектларның һәм инженерлык коммуникацияләренең югары дәрәҗәдә таушалган булуы белән характерлана. Коммуналь инфраструктура объектларының һәм корылмаларының югары дәрәҗәдә мораль һәм физик яктан тузуы җәмгыятьнең, шул исәптән яңа торак төзелеше һәм яңа социаль инфраструктура объектлары төзелеше белән бәйле булган ихтыяҗларының артуын тәэмин итә алмый.<br>Коммуналь челтәрләрнең тузуы шулай ук аварияләргә китерә. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының авария-техник запасыннан материаллар һәм җиһазлар бүлеп бирү үтенече белән ел саен торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе оешмаларыннан 200 дән артык мөрәҗәгать килә.<br>Республика һәм муниципаль милек рәвешендәге күп кенә оешмалар республиканың авыл районнарында коммуналь фондлар буларак булдырылган һәм эшләп килә. Биредә җиһазлар югары дәрәҗәдә тузган һәм озак вакыт буш торган. Мондый оешмаларның төп кулланучылары – авыл җирлекләрендә яшәүче, хезмәтләр өчен түләү дәрәҗәсе түбән булган халык һәм бюджет оешмалары.<br>Коммуналь объектларның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге түбән булу шартларында, шул исәптән коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр үсешенең гамәлдәге чикләүләре белән бәйле рәвештә, хосусый инвесторларны җәлеп итү буенча башкарылган эш нәтиҗәсендә Татарстан Республикасында ирешелгән күрсәткечнең максатчан күрсәткечен киметмәү мөһим булып тора.</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Кыенлыклар:<br>төп фондларның югары дәрәҗәсе тузуы;<br>күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;<br>җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы предприятиеләрнең конкурентлыкка сәләте җитәрлек булмавы;<br>коммуналь объектларның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге түбән булуы</td><td colspan="7">Бурычлар: җылылык һәм электр энергиясен катнаш эшләп чыгару станцияләрендә җитештерү куәтләрен үстерү;<br>гамәлдәге җылылык белән тәэмин итү чыганакларын, магистраль һәм квартал җылылык челтәрләрен реконструкцияләү һәм модернизацияләү;<br>җылылык белән тәэмин итү чыганакларына хезмәт күрсәтүче инженер һәм техник составның, магистраль һәм квартал җылылык челтәрләренең һөнәри әзерлеге дәрәҗәсен арттыру;<br>җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы предприятиеләрнең конкурентлык сәләтен арттыру;<br>җылылык белән тәэмин итү базарында хезмәт күрсәтү сыйфатын арттыру;<br>җылылык энергиясе җитештерү объектлары идарәсен хосусый операторларга концессия килешмәләре нигезендә тапшыру.<br>Максат (төп күрсәткеч): барлык милек рәвешләрендәге оешмалар җылылык</td></tr>
</table>

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | энергиясен файдалы җибәрүнең гомуми күләмендә хосусый милек рәвешендәге оешмалар тарафыннан җылылык энергиясен җибәрү өлешен саклап калу, процентларда.<br>Төп күрсәткечләр:<br>01.01.2018 – 67 %<br>01.01.2019 – 67 %<br>Фаразлана торган күрсәткечләр:<br>01.01.2020 – 67 %<br>01.01.2021 – 67 %<br>01.01.2022 – 67 % | | | | | | |
| 6.1 | Концессия килешмәләре нигезендә җылылык белән тәэмин итү объектларын хосусый операторларга тапшыру | Концессия килешмәләре нигезендә хосусый операторларга тапшырылган җылылык белән тәэмин итү объектлары саны | берәмлек | 295 | 298 | 310 | 320 | 330 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 6.2 | Җылылык белән тәэмин итү базарында хезмәт күрсәтүләр кулланунын нәтиҗәлелеген арттыруның муниципаль программаларын булдыру | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округлары тарафыннан булдырылган энергия нәтиҗәлелеге программалары саны | берәмлек | 0 | 10 | 20 | 30 | 45 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 7. Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм төяп озату буенча хезмәтләр базары | | | | | | | | | | |
| Ел саен республикада каты коммуналь калдыклар (алга таба – ККК) белән эш итү объектларына транспортлана торган 12 000,0 мең куб. метрдан артык каты коммуналь калдыклар барлыкка килә. 2018 елда каты көнкүреш калдыкларын транспортлауны гамәлгә ашыручы хосусый милек рәвешендәге оешмалар өлешенә әлеге хезмәт күрсәтү базарының гомуми күләменнән 89% туры килде.<br>«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ККК белән эш итү, шул | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исәптән КККны транспортлау төбәк операторлары тарафыннан ККК белән эш итү (Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурс сайлап алулары нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән статус бирелгән юридик затлар) белән тәэмин ителә.<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 641 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2016 елның 12 ноябрендәге 1156 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыклар белән эш итү кагыйдәләре буенча төбәк операторы ККК белән, шул исәптән аларны җыю һәм төяп озату белән, мөстәкыйль рәвештә яки ККК (ККК белән эш итүче хуҗалык итүче субъектлар) белән эш итүче операторларны җәлеп итү аша хезмәттәшлек итә. | | | | | | | | | | |
| | Кыенлыклар: ККК белән эш итү өлкәсендә өстенлекле урын алып торучы ККК белән эш итүче региональ оператор, үзе үткәргән сатулар нәтиҗәләре буенча килешүләр нигезендә, КККны төяп озату буенча хезмәтләр күрсәтү өчен хуҗалык итүче субъектларны үзенә җәлеп итәргә хакы бар. | | | Бурычлар: КККны төяп озату базарында төбәк операторы булуын исәпкә алып, хосусый оешмалар арасында конкурентлыкны булдыру;<br>КККны җыю һәм төяп озату базарында хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын арттыру.<br>Максат (төп күрсәткеч): КККны җыю һәм төяп озату базарында шәхси милек рәвешендәге оешмаларны өлешен саклап калу, процентларда.<br>Төп күрсәткечләр:<br>01.01.2018 – 89 %<br>01.01.2019 – 89 %<br>Фаразлана торган күрсәткечләр:<br>01.01.2020 – 89 %<br>01.01.2021 – 89 %<br>01.01.2022 – 89 % | | | | | | |
| 7.1 | КККны төяп озату буенча яңа эшкуарлык инициативалары һәм хосусый инициативаларны стимуллаштыру | Эшләүче һәм потенциаль эшкуарлар һәм оешмалар белән түгәрәк өстәлләр, вебинарлар, консультацияләр уздыру | берәмлек | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;<br>ККК белән эш итү буенча төбәк операторлары (килешү буенча) |
| | | Эшләүче һәм потенциаль эшкуарлар һәм оешмалар белән консультацияләр уздыру | бар/юк | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | |

<table>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td><td>10</td><td>11</td></tr>
<tr><td colspan="11">8. Күпфатирлы йортта бина милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм агымдагы ремонтлау эшләрен башкару базары</td></tr>
<tr><td colspan="11">2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында идарәче компанияләр (алга таба – ИК) карамагында булган күпфатирлы йортларның (алга таба – КФЙ) гомуми мәйданы – 49 469,1 мең кв.метр, шулардан: муниципаль милек рәвешендәге ИК идарәсендә 259,00 мең кв. метр; хосусый милек рәвешендәге идарәче компания идарәсендә – 49 210,1 мең кв. метр. Чагыштыру өчен: 2018 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында идарәче компанияләр (алга таба – ИК) карамагында булган күпфатирлы йортларның гомуми мәйданы – 46 407,4 мең кв.метр, шулардан: муниципаль милек рәвешендәге идарәче компания идарәсендә – 880,6 мең кв. метр; хосусый милек рәвешендәге идарәче компания идарәсендә – 45 526,8 мең кв. метр.<br>Шулай итеп, хосусый милек рәвешендәге ИК өлешенә базарның гомуми күләменнән 99,5% туры килә.<br>Күрсәткечләрнең югары булуына карамастан, хәл ителүе көндәшлекле мохитнең киләчәк үсешенә ярдәм итәчәк кайбер бурычлар бар.<br>Республикада гамәлдә булган лицензияләр белән барлыгы 288 ИК эшли, шулардан муниципаль милек рәвешендәге ИК саны – 13. Шактый зур финанслар кертелү, идарә итү системасының абсолют ачык булмавы сәбәпле торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе, шул исәптән күпфатирлы йортта бина милекчеләренең гомуми милкен карап тоту буенча хезмәтләр «коррупция куркынычы булган өлкәләр» рәтенә керә. Аерым затларның үз вазыйфаи хәленнән файдалану очраклары билгеле булган респондентлардан һәр сигезенче респондент (13,2%) торак-коммуналь хуҗалык өлкәсен (коррупциягә каршы мониторинг) билгеләп үтә.<br>Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә килеп туган кыенлыклар турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен электрон рәвештә бастырып чыгару мөмкинлекләрен арттыру килеп туган кыенлыкларны оператив рәвештә хәл итәргә ярдәм итә һәм Татарстан Республикасы халкы әлеге хезмәттән бик еш файдалана. Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары буенча торак-коммуналь хезмәтләр өлкәсендәге кыенлыклар турында гражданнарның басылып чыккан мөрәҗәгатьләре саны арта бара. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә операцион процессларны оештыру һәм идарә итү нәтиҗәлелеген арттыруда төп юнәлешләрне билгеләргә мөмкинлек бирә</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Кыенлыклар: КФЙ белән идарә итү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты түбән булу;<br>КФЙ карап тоту һәм ишегалды территорияләрен төзекләндерү хезмәтләрен яхшырту ихтыяҗы;<br>идарәче оешмалар хезмәткәрләренең түбән квалификация дәрәҗәсе;<br>тармакны модернизацияләү һәм заманча технологияләр кертү өчен кирәкле инвестицияләрнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;<br>идарәче оешмаларның ишегалды территорияләрен төзекләндерү мәсьәләләрен хәл итү өчен үз әйләнешләрендәге акчалары җитмәү</td><td colspan="7">Бурычлар: КФЙ белән идарә итү буенча хезмәтләр күрсәтү базарында хезмәт күрсәтүне тәкъдим итә ала торган лицензияле оешмалар санын арттыру;<br>идарәче һәм ресурс белән тәэмин итүче оешмаларның торак-коммуналь хезмәтләр сыйфатын арттыру;<br>КФЙ белән идарә итү һәм гомум йорт милкен карап тоту буенча килеп туган кыенлыклар турында идарәче компанияләргә үз вакытында хәбәр итүнең электрон формаларын һәм мәйданчыкларын үстерү;<br>барлык милек рәвешләрендәге хуҗалык итүче субъектлар өчен базарга чыгуда тигез шартлар тәэмин итү;<br>хезмәт күрсәтүнең яңа технологияләрен активлаштыру хисабына КФЙны карап тотуның үзкыйммәтен киметү;<br>идарәче оешмалар хезмәткәрләренең квалификация дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән даими рәвештә чаралар үткәрү.</td></tr>
</table>

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Максат (төп күрсәткеч): КФЙ биналарының гомуми милкен карап тоту һәм агымдагы ремонтлау эшләрен башкару өлкәсендә хосусый милек рәвешендәге оешмалар өлешен югары дәрәҗәдә саклап калу, процентларда.<br>Төп күрсәткечләр:<br>01.01.2018 – 98,1 %<br>01.01.2019 – 98,2 %<br>Фаразлана торган саннар:<br>01.01.2020 – 80 % *<br>01.01.2021 – 86,1 %<br>01.01.2022 – 86,3 %<br>* 2020 елда күрсәткечләрнең кимүе лицензия алырга кирәклек белән аңлатыла (һәр 5 ел саен), нәтиҗәдә, ИКнең бер өлеше гамәлдәге законнар кысаларында лицензия алмыйча базардан китәчәк | | | | | | |
